РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**КАРАР** **КАРАР**

**10.02.2020** Кукмара шәһәре **№ 144**

«2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районы халкын сыйфатлы торак
һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү,
территорияләрне төзекләндерү хезмәте белән тәэмин итү»
муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 25 декабрендә 827 номерлы карары белән расланган «2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү, территорияләрне төзекләндерү хезмәте белән тәэмин итү» муниципаль программасын әлеге карарның кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А. Х. Гарифуллин**

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитет җитәкчесенең 2020 елның 144 номерлы карарына кушымта

**«2018 – 2020 ЕЛЛАРГА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХАЛКЫН СЫЙФАТЛЫ ТОРАК ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫК ХЕЗМӘТЛӘРЕ КҮРСӘТҮ, ТЕРРИТОРИЯНЕ ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ»**
**МУНИЦИПАЛЬ ПРОГРАММАСЫ**

Муниципаль программа паспорты

| | |
|---|---|
| Дәүләт программасының исеме | «2018 – 2020 елларга Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре күрсәтү, территорияне төзекләндерү белән тәэмин итү» |
| Дәүләт заказчысы | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының район Советы |
| Программаны төп эшләүчеләр | Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты, инфраструктура үсеше бүлеге. |
| Программаның төп максаты | Кукмара муниципаль районы халкын торак төзелешенә ярдәм итү һәм аны үстерү механизмнарын гамәлгә ашыру һәм торак базарында ихтыяҗны стимуллаштыру юлы белән үтемле һәм сыйфатлы торак белән тәэмин итү.<br>Торак фондының сыйфатын һәм энергия нәтиҗәлелеген, халыкның коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителеше, коммуналь хезмәтләрнең ышанычлылыгы һәм сыйфаты дәрәҗәсен арттыру. |
| Программаның төп бурычлары | Торак сатып алганда һәм торак шартларын яхшыртуда гражданнарга ярдәм итү буенча Дәүләт йөкләмәләрен һәм социаль гарантияләрне үтәү; торак төзелешендә инвестицион активлыкны стимуллаштыру өчен шартлар тудыру, гражданнарның имин һәм уңайлы яшәү шартлары тудыру;<br>халыкны билгеләнгән санитар-эпидемиологик<br>кагыйдәләргә туры килә торган чиста су белән тәэмин итү,<br>коммуналь системаларның ышанычлылыгына һәм ресурс нәтиҗәлелегенә ирешү; торак-коммуналь хуҗалыкның энергия нәтиҗәлелеген күтәрү;<br>архитектура, шәһәр төзелеше, төзелеш, төзелеш материаллары сәнәгате, торак өлкәсендә һәм коммуналь хуҗалык өлкәсендә дәүләт сәясәтенең нәтиҗәлелеген арттыру өчен шартлар тудыру. |
| Программаны гамәлгә ашыру сроклары һәм этаплары | 2018 – 2020 еллар |
| Ярдәмче программалар исемлеге | «2018 – 2020 елларда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау муниципаль программасы чараларын гамәлгә |

| | |
|---|---|
| | ашыру» **Ярдәмче программасы**<br>«2018 – 2020 елларга архитектура, шәһәр төзелеше, төзелеш, төзелеш материаллары сәнәгате, торак һәм коммуналь хуҗалык өлкәсендә муниципаль сәясәтне гамәлгә ашыру» **Ярдәмче программасы**<br>«2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районы территориясен төзекләндерү» **Ярдәмче программасы**. |
| Финанслау күләме | Программаны финанслауның гомуми күләме 30 295 мең сум тәшкил итә,<br>шул исәптән:<br>2018 елда – 4 388,0 мең сум;<br>2019 елда – 4 452,9 мең сум;<br>2020 елда – 21 454,1 мең сум |
| Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре | Программа чараларын гамәлгә ашыру түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны торак урыннары белән тәэмин итү;<br>- яшь гаиләләрнең торак шартларын яхшырту;<br>- торак фондының гомуми күләмендә тузган һәм авария хәлендәге торак фондының өлешен киметү;<br>- бер кешегә уртача 26,1 метрга кадәр туры килә торган торак биналарның гомуми мәйданын арттыру;<br>2012 елның 1 гыйнварына кадәр авария хәлендә дип танылган авария хәлендәге торак фондын бетерү;<br>- зыянга эшләүче торак-коммуналь хуҗалык оешмалары өлешен киметү;<br>- челтәргә тапшырылган суның суммар күләмендә аккан суның һәм исәпкә алынмаган чыгымның өлешен киметү;<br>- торак фондының гомуми мәйданында төзекләндерүнең барлык төрләре белән тәэмин ителгән торак фонды мәйданының өлешен арттыру. |

Программаны тормышка ашыру өлкәсенә гомуми характеристика,
шул исәптән, аларны хәл итүгә Программа юнәлдерелгән проблемалар

Гражданнарның торакка булган конституцион хокукларын гамәлгә ашыру, кешенең төп ихтыяҗларын тәэмин итү – гаилә учагы, үзе һәм якыннары өчен лаеклы һәм уңайлы яшәү шартлары булдыру – теләсә кайсы хокукый дәүләтнең фундаменталь бурычларыннан берсе. Үз торагы булу кешенең яшәешендә милләтнең сәламәтлеген, гаилә формалаштыруны һәм гаилә кыйммәтләрен саклауны, демографик вәзгыятьне тотрыкландыруны һәм уңай үстерүне тәэмин итә торган төп кыйммәтләреннән, аның төп ихтыяҗларыннан берсе булып тора, Бу – кешеләрнең иртәгәсе көнгә ышаныч чыганагы һәм җәмгыятьтә тотрыклылык терәге.

Дәүләт торак сәясәтенең өстенлекле юнәлешләре: торак алу мөмкинлеген арттыру, торак төзелеше күләмен арттыру һәм коммуналь инфраструктура объектларын модернизацияләү, гражданнарның билгеләнгән категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәү – «Россия гражданнарына – үтемле һәм уңайлы торак» өстенлекле илкүләм проектында чагылыш тапты.

Районда торак төзелеше өч төп юнәлеш буенча үсә:
социаль ипотека программасы;
күпфатирлы инвестицион торак;
азкатлы төзелеш.

Тузган торакны бетерү программасына алмашка республикада социаль җайлаштырылган масштаблы торак программасы – Социаль ипотека программасы килде; Программаның гражданнарга торак урыннары бирү буенча чаралары «Татарстан Республикасында торак төзелешен үстерүгә дәүләт ярдәме турында» 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Социаль ипотека программасын тормышка ашыру операторы – «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерцияле булмаган оешмасы. Фондны гамәлгә куючы – Татарстан Республикасы Президенты исеменнән Татарстан Республикасы. Программа торак шартларын яхшыртуга чиратта торучы гражданнар, нигездә, шәһәр төзүче предприятиеләр һәм бюджет өлкәсе хезмәткәрләре өчен билгеләнгән. Әлеге категория гражданнар, фатир бәясенең 0 дән 30 га кадәр проценты күләмендә беренчел взносны түләп, еллык 7 процент белән 28,5 елга кадәр түләүләрне кичектереп тору шартларында фатир алалар.

Социаль ипотека республика программасы буенча гражданнарга ярдәм итү «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерцияле булмаган оешмасы тарафыннан заманча проектлар буенча типик сыйфатлы торак төзүне республика предприятиеләре акчалары хисабына финанслауны күздә тота.

Торак төзелешен стимуллаштыруның бер юнәлеше – торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт ярдәме күрсәтү. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2015 – 2020 елларга «Торак» федераль максатчан программасы турында» 2006 елның 21 мартындагы 153 номерлы карары белән расланган «2015 – 2020 елларга «Торак» федераль максатчан программасы» (алга таба – «Торак» ФМП) федераль законнарында билгеләнгән гражданнар категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча Дәүләт йөкләмәләрен үтәү Ярдәмче программасы эшли. түбәндәге чаралар тормышка ашырыла: хәрби хезмәттән азат ителгән гражданнарны, чернобыльчеләрне, Ерак Төньяк районнарыннан чыгып китәргә мәҗбүр булган кешеләрне торак белән тәэмин итү. Яшь гаиләләргә экономик класслы торак сатып алу яки экономик класслы индивидуаль торак йорт төзү өчен социаль түләүләр бирүне күз алдында тота торган «Яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» Ярдәмче программасы  Моннан тыш, районда күп балалы гаиләләрне һәм ятим балаларны торак белән тәэмин итү буенча чаралар тормышка ашырыла. 2010 елдан Бөек Ватан сугышы ветераннарының торак шартларын яхшырту программасы тормышка ашырыла. Кукмара муниципаль районында «ТР Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» «Аренда торагы» НО программасын тормышка ашыру планлаштырыла. Программаның максаты – үтемле арендалы торак базарын формалаштыру һәм арендалы торакка мохтаҗ гражданнар өчен коммерцияле булмаган торак фондын үстерү. Программада бюджет оешмалары һәм учреждениеләре хезмәткәрләре, элек гражданнарның торак шартларын яхшырту буенча дәүләт программаларында катнашмаган һәм вакытлыча торакка мохтаҗ булган предприятиеләр хезмәткәрләре катнаша ала.

**«2018 – 2020 елларда Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау муниципаль программасы чараларын гамәлгә ашыру» Ярдәмче программасы**

Ярдәмче программа чараларын үтәү Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган региональ программасы кысаларында гамәлгә ашырыла.

Ярдәмче программаның максаты

Гражданнарның имин һәм уңайлы яшәү шартларын булдыру; торак фондын саклап калу, торгызу һәм сыйфатын арттыру, Татарстан Республикасында күп фатирлы йортларның техник торышын яхшырту.

Ярдәмче программаның төп бурычлары

Күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлауны нәтиҗәле планлаштыру һәм вакытында үткәрүне оештыру, озак сроклы материаллар һәм ресурсларны саклау технологияләрен кулланып, капиталь ремонт үткәргәндә нәтиҗәле техник карарлар һәм комплекслы куллану.

Ярдәмче программа чараларын уңышлы гамәлгә ашыру торак фондын Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры китерүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Муниципаль ярдәмче программаны финанс белән тәэмин итү.

Ярдәмче программаны финанслау чыганакларының берсе булып 13164,0 мең сум күләмендә Кукмара районы бюджеты чаралары тора, шул исәптән

2018 ел – 4388,0 мең сум,
2019 ел – 4388,0 мең сум,
2020 ел – 4388,0 мең сум.

Ярдәмче программаны финанс белән тәэмин итү ел саен аныкланырга һәм төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакыты

Ярдәмче программаны тормышка ашыру срогы – 2018 – 2020 еллар.

**Кукмара муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча төбәк программасын 2018 елда тормышка ашыруның Кыска сроклы планы.**

I. Гомуми нигезләмәләр

Кукмара муниципаль районы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны тормышка ашыруның Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 31 декабрендәге 524 номерлы карары белән расланган әлеге кыска сроклы планы (алга таба – Кыска сроклы план, Озак сроклы программа) Россия Федерациясе Торак кодексы, 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы «Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга ярдәм итү фонды турында»

Федераль закон (алга таба – Федераль закон), «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба – Татарстан Республикасы Законы) нигезендә региональ программаны тормышка ашыру, күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт үткәрү срокларын төгәлләштерү, күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләрнең һәм (яки) эшләрнең планлаштырылган төрләрен төгәлләштерү, капиталь ремонт үткәрүгә дәүләт ярдәме, муниципаль ярдәм төрләрен һәм күләмен билгеләү максатларында эшләнгән.

## II. Кыска сроклы планның төп максатлары һәм бурычлары

Кыска сроклы планның төп максатлары:

Кукмара муниципаль районында торак фондын саклап калу, торгызу һәм аның сыйфатын күтәрү;

гражданнарның имин һәм уңайлы яшәү шартларын тудыру;

күп фатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь ремонт үткәрүгә дәүләт ярдәме, муниципаль ярдәм.

Кыска сроклы планның төп бурычлары:

халык белән актив агитация-аңлату эшләре алып бару;

Кыска сроклы план башкаручыларны сайлап алу буенча ачык һәм гавами процедураларны эшләү һәм үтәү;

озак сроклы материаллар һәм ресурсларны саклау технологияләрен кулланып, капиталь ремонт үткәргәндә нәтиҗәле техник карарлар һәм комплекслылыкны куллану.

Кыска вакытлы планны тормышка ашыру срогы – 2018 ел.

Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру гомуми мәйданы 7070,7 кв. метр булган 7 күпфатирлы йортта 375 гражданга имин һәм уңайлы яшәү шартларын тәэмин итәргә тиеш.

## III. 2018 елда күпфатирлы йортларга капиталь ремонт үткәрү күләмнәре

.

| Күпфатирлы йортларның гомуми милеген капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Үлчәү берәмлеге | .<br>. |
|---|---|---|
| Түбә ремонтлау | мең кв. метр | 2,915 |
| Йорт эчендәге инженерлык челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән: | | |
| электр белән тәэмин итү | мең метр | 1,0519 |
| җылылык белән тәэмин итү | пог.метр | 0,324 |
| су белән тәэмин итү | мең метр | 0,176 |
| пычрак суны чыгару | мең метр | 0,220 |
| Күпфатирлы йортларда гомуми милеккә караган подвал биналарын ремонтлау | мең кв. метр | 0,832 |
| Фасадны ремонтлау | мең кв. метр | 4,409 |
| Күпфатирлы йортта подъездларны ремонтлау | мең кв. метр | 1,988 |

## IV. Ресурслар белән тәэмин итү

Кыска вакытлы планны финанслау чыганаклары – Татарстан Республикасы һәм (яки) җирле бюджетлар Фонды, бюджеты, торак милекчеләре ширкәтләре, торак, торак-төзелеш кооперативлары (алга таба – ТСЖ, ЖК, ЖСК) әгъзалары яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары яисә күпфатирлы йорттагы биналарның милекчеләре акчалары.

2018 елда күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлауга финанс чаралары ихтыяҗы күләме.

| Күпфатирлы йортларның гомуми милеген капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге | Финанслау ихтыяҗы, мең сум |
|---|---|
| Түбә ремонтлау | 5668,705 |
| Йорт эчендәге инженерлык челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән: | |
| электр белән тәэмин итү | 311,108 |
| җылылык белән тәэмин итү | |
| су белән тәэмин итү | 183,841 |
| пычрак суны чыгару | 328,416 |
| Күпфатирлы йортларда гомуми милеккә караган подвал биналарын ремонтлау | 226,979 |
| Фасадны ремонтлау | 11688,390 |
| Күпфатирлы йортта подъездларны ремонтлау | 1920,034 |
| Проект документларына дәүләт экспертизасын эшләү һәм үткәрү | 612,088 |
| Төзелеш контролен тормышка ашыру | 204,151 |
| Техник паспортлар әзерләү | 87,643 |
| Барлыгы: | 21 231 359,79 |

## V. Капиталь ремонт буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләрнең чик бәясе

2018 елга күпфатирлы йортларда биналарның гомуми мәйданының 1 кв.метрына исәпләнгән капиталь ремонт буенча хезмәтләрнең һәм (яки) эшләрнең чик бәясе 14 мең сум тәшкил итә.

Шул ук вакытта әлеге Кыска сроклы планга кертелгән күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау өчен хезмәтләрнең һәм (яки) эшләрнең чик бәясе размеры эш төрләре

буенча Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы боерыгы белән раслана.

Капиталь ремонт буенча хезмәтләрнең һәм (яки) эшләрнең чик хакын арттыру, шулай ук кыска сроклы планда каралмаган хезмәтләр һәм (яки) эшләр өчен түләү күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең капиталь ремонт өчен кертем рәвешендә капиталь ремонт өчен минималь кертем күләменнән артык түләнә торган акчалары хисабына тормышка ашырыла.

## VI. Кыска вакытлы планны гамәлгә ашыру механизмы

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

Төбәк программасын тормышка ашыруның кыска сроклы (еллык) муниципаль планнарын тикшерүне гамәлгә ашыра, формалаштыра һәм министрлыкка җибәрә;

Министрлыкка муниципаль берәмлек тарафыннан финанс ярдәме күрсәтү шартларын үтәүне раслаучы норматив хокукый актларның күчермәләрен һәм башка документлар тапшыра;

капиталь ремонт үткәрү өчен подрядчы оешмаларны сайлау процедурасында катнаша;

Федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм торак законнары нигезендә әлеге Кыска сроклы планда билгеләнгән күләмдә капиталь ремонт эшләрен финанслашуга җирле бюджет акчаларын күчерә;

региональ оператор белән килешү (шартнамә) нигезендә күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләргә техник заказ бирүче функцияләрен башкара;

капиталь ремонт буенча башкарылган эшләр актларын, эшләрне кабул итү актларын, ккүпфатирлы йортка капиталь ремонт ясау өчен расланган чыгымнар сметасында каралмаган акчадан файдалану очракларыннан тыш, шулай ук ул арткан очракта килештерә;

күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлау буенча эшләр башкаруга бүлеп бирелә торган акчаларның максатчан кулланылышын контрольдә тота;

тиешле муниципаль берәмлек буенча кыска сроклы планны Министрлык тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә гамәлгә ашыру максатларында мәгълүматлар базасын (шул исәптән күпфатирлы йортларда торак һәм торак булмаган биналарның мәйданнары буенча) булдыра һәм актуаль халәттә тота;

Министрлыкка һәм Кыска сроклы планның башка башкаручыларына Фондка хисапларны формалаштыру өчен кирәкле документларны һәм белешмәләрне тапшыра.

ТСЖ, ТТК, ЖК, УО:

капиталь ремонт өчен взнослар буенча милекчеләргә ай саен түләүләрне хисаплыйлар, биналарның милекчеләреннән капиталь ремонт өчен взнос рәвешендә түләнә торган акча җыюны гамәлгә ашыралар, капиталь ремонт фондын региональ оператор исәбендә формалаштырганда, капиталь ремонт өчен милекчеләрнең кертемнәрен региональ оператор счетына күчерәләр, капиталь ремонт һәм торак фонды объектларының торышы мониторингы дәүләт программасын формалаштыру һәм үтәү мониторингы буенча интеграцияләнгән мәгълүмати-аналитик системага һәр милекче буенча начисление һәм түләү турында мәгълүматны https://bars-monjf.tatar.ru/monjf/ web-адресы белән йөклиләр (выгружают);

капиталь ремонт өчен түләүләр буенча бина милекчеләренең бурычлары барлыкка килүгә юл куймау буенча чаралар күрәләр;

тикшерү актларын, капиталь ремонт буенча эшләр күләменә дефект ведомостьларын килештерәләр;

дәүләт экспертизасы бәяләмәсен алып, проект документациясен әзерләүне тәэмин итәләр;

Министрлык раслаган тәртип нигезендә сайлап алуны оештыра;

капиталь ремонт үткәрү өчен подрядчы оешмаларны сайлау процедурасында катнашалар;

биналарның милекчеләренә капиталь ремонт башлану вакыты, кирәкле хезмәтләр һәм (яки) эшләрнең исемлеге, аларның бәясе, күпфатирлы йортта гомуми милекне капиталь ремонтлауны финанслау тәртибе һәм чыганаклары турында һәм Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә капиталь ремонт үткәрүгә бәйле башка тәкъдимнәр тапшыралар,

капиталь ремонт объектларына кертүне гамәлгә ашыралар;

күпфатирлы йортларда капиталь ремонтның үз вакытында һәм сыйфатлы башкарылуын контрольдә тота, шулай ук капиталь ремонттан соң күп фатирлы йортларны файдалануга тапшыру актларына һәм капиталь ремонт тәмамланган объектларны тикшерү актларына кул кую хокукы белән кабул итүдә катнаша.

Бина милекчеләре:

тикшерү актларын, капиталь ремонт буенча эшләр күләменә дефект ведомостьларын килештерәләр;

күпфатирлы йортларда капиталь ремонтның үз вакытында һәм сыйфатлы башкарылуын контрольдә тотуда, шулай ук капиталь ремонтлау тәмамланган объектларны тикшерү актларына һәм файдалануга тапшыру актларына кул кую хокукы белән аларны кабул итүдә катнашалар.

Подрядчы оешмалар:

Кыска сроклы план һәм подряд шартнамәсендә билгеләнгән срокларда күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрне башкаруны тәэмин итәләр;

КС-2, КС-3 формасы буенча башкарылган эшләр актларын формалаштыралар;

күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләр башкарганда төзелеш контролен гамәлгә ашыралар;

күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрне сыйфатлы һәм үз вакытында башкару өчен җавап тоталар;

объектны файдалануга тапшыруны тәэмин итәләр;

подряд шартнамәсендә каралган башка эшләрне башкаралар.

Техник заказчы функцияләрен башкаручы оешмалар:

проект документларын, шул исәптән сметаны әзерләүне һәм раслауны гамәлгә ашыралар;

күпфатирлы йортларны капиталь ремонтлаганда төзелеш контролен гамәлгә ашыралар;

башкарылган эшләрне кабул итүдә катнашалар, башкарылган эшләр актларын килештерәләр;

объектны эксплуатациягә кабул итүдә катнашалар, объектны эксплуатациягә кабул итү актын килештерәләр;

күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау буенча эшләрне сыйфатлы һәм үз вакытында башкару өчен җавап тоталар;

техник заказчының законнарда каралган башка функцияләрен гамәлгә ашыралар.

Кыска вакытлы планны планлаштыру, үтәү, контрольдә тоту һәм мониторинглау «Торак фонды мониторингы» ярдәм мәгълүмат продуктында гамәлгә ашырыла.

## «2018 – 2020 елларга архитектура, шәһәр төзелеше, төзелеш, төзелеш материаллары сәнәгате, торак һәм коммуналь хуҗалык өлкәсендә муниципаль сәясәтне гамәлгә ашыру» Ярдәмче программасы

Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә торак төзелеше территориаль планлаштыруның эшләнгән һәм расланган документлары нигезендә гамәлгә ашырылырга тиеш. Күрсәтелгән документларны эшләү вәкаләтләре җирле үзидарә органнарының җаваплылыгы өлкәсенә кертелгән.

Массакүләм торак төзелеше һәм территорияләрне комплексны үзләштерү һәм үстерү шәһәр төзелешен дөрес, икътисади һәм техник яктан нигезләнгән планлаштырудан башка

мөмкин түгел. Архитектура һәм проектлау өлкәсендә җитди кадрлар потенциалы, булган ресурслар, административ һәм финанс потенциалы, күп кенә мәсьәләләрне профильле проект институтлары аша үзәкләштереп хәл итү – болар барысы да районда бу юнәлештә җитди нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирде.

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районында 30 җирлек исәпләнә (1 шәһәр һәм 29 авыл җирлеге, алар составына 124 торак пункт керә).

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы таләпләренә туры китереп, территориаль планлаштыруның түбәндәге документлары таләп ителә:

- районның территориаль планлаштыру схемалары;
- җирлекләрнең 30 генераль планы;
- җирдән файдалану һәм төзелешнең 30 кагыйдәләре.

Хәзерге вакытта районның территориаль планлаштыру схемасын, Кукмара штп һәм районның барлык авыл җирлекләренең генераль планнарын, Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләү төгәлләнде, алар закон нигезендә җирлекләрнең тиешле вәкиллекле органнары тарафыннан кабул ителде һәм расланды

Торак төзелешен һәм төзелеш индустриясен үстерүдә иң мөһим һәм өстенлекле мәсьәләләрнең берсе – заманча шәһәр төзелеше һәм экология таләпләренә җавап бирә торган төзелеш материаллары җитештерүдә энергия һәм ресурс саклау технологияләрен куллану.

Торак төзелеше базарының ихтыяҗларын тәэмин итүче мөһим фактор булып, төзелеш материаллары сәнәгатенең хәзерге торышы һәм потенциалы тора.

Татарстан Республикасының төзелеш материаллары сәнәгатенең үсеш алган базасы бар, ул 400 ләп эре һәм урта предприятиене, шул исәптән җыелма тимер-бетон, бетон, товар бетоны һәм раствор җитештерү буенча 60 ка якын заводны үз эченә ала.

Татарстан Республикасы төзелеш материаллары сәнәгате төзелеш комплексының ихтыяҗларын тулысынча тәэмин итә – бетон, эретмә, бетон һәм тимер-бетон конструкцияләре, силикат кирпеч, тәрәзә һәм ишек блоклары, ком-гравий катнашмасы, төзелеш комы; өлешчә-җылылык изоляциясе, полимер, йомшак түбә материаллары, лицевой кирпеч, вак таш, металл эшләнмәләр һәм конструкцияләр.

Торак төзелешен һәм төзелеш индустриясен үстерүдә иң мөһим һәм өстенлекле мәсьәләләрнең берсе – заманча шәһәр төзелеше һәм экология таләпләренә җавап бирә торган төзелеш материаллары җитештерүдә энергия һәм ресурс саклау технологияләрен куллану.

Төзелеш комплексындагы төп проблемалар арасында шуны билгеләп үтәргә кирәк:

артык күп административ каршылыклар булу;

инженерлык һәм юл инфраструктурасы, социаль өлкә объектлары (мәктәпләр һәм балалар бакчалары) белән җиһазландырылган җир кишәрлекләре булмау;

инженерлык инфраструктурасын төзүгә һәм реконструкцияләүгә шәхси инвестиция һәм кредит ресурсларын җәлеп итү механизмнары булмау.

## Ярдәмче программаның максаты

Архитектура, шәһәр төзелеше, төзелеш, төзелеш материаллары сәнәгате, торак өлкәсендә һәм коммуналь хуҗалык өлкәсендә дәүләт сәясәтенең нәтиҗәлелеген арттыру юлы белән Кукмара районының тотрыклы социаль-икътисади үсешен тәэмин итү

## Ярдәмче программаның бурычлары

Территориаль планлаштыру һәм шәһәр төзелешен зоналаштыру нигезендә Кукмара районын үстерүне тәэмин итү, гражданлык һәм сәнәгать төзелеше үсеше шартларын булдыру, гражданнарның яшәү стандартларын һәм күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын тәэмин итү

## Муниципаль ярдәмче программаны финанс белән тәэмин итү.

Ярдәмче программаны финанслау чыганакларының берсе булып 15 171,9 мең сум күләмендә Кукмара районы бюджеты акчалары тора, шул исәптән

2018 ел – 0 мең сум,

201 ел – 64,9 мең сум,

2020 ел – 15 107,0 мең сум.

Ярдәмче программаны финанс белән тәэмин итү ел саен аныкланырга һәм төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакыты

Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакыты – 2018 – 2020 еллар.

**«2018 – 2020 елларга Кукмара муниципаль районы территориясен төзекләндерү» ярдәмче программасы.**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнгән.

Программаны эшләгәндә җирлек территориясендә урнашкан район халкының, предприятие һәм оешмаларның җирлек территориясен төзекләндерү буенча тәкъдимнәре исәпкә алынды.

Проблеманың эчтәлеге һәм аны хәл итү кирәклеген нигезләү.

Кукмара муниципаль районы территориясен төзекләндерүгә зур игътибар бирергә кирәк, чөнки район территориясе бик зур, анда 124 торак пункт урнашкан һәм даими 57,2 мең кеше яши. Поселок территориясенең мөһим өлеше булган ишегалды территорияләре берничә функция башкара:

- беренчедән, бу зур антропоген йөкләнеш зонасы, шуңа күрә биредә җәяүлеләр өчен юллар җитәрлек булырга тиеш;
- икенчедән, бу – тыныч һәм актив ял итү зоналарын үз эченә алган ял һәм аралашу урыны, шуңа күрә һәр ишегалды һәм скверның алыштыргысыз элементы – эскәмия, урналар, кечкенә балалар өчен уен мәйданчыклары, спорт мәйданчыклары.

Муниципаль ярдәмче программаның максаты һәм бурычлары

Халыкка яшәү һәм күпләп ял итү өчен уңай шартлар тудыру, район җирлекләре территорияләрен төзекләндерү. Халыкның күпләп ял итү һәм спорт урыннарын төзекләндерү.

Муниципаль ярдәмче программаны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре.

Программа чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә түбәндәгеләр эшләнәчәк:

- авыл җирлекләре өчен техник паспортлар әзерләү;
- күмү урыннарын (зиратларны) төзекләндерү;
- авыллардагы юлларны ремонтлау.

Муниципаль ярдәмче программаны финанс белән тәэмин итү.

Ярдәмче программаны финанслау чыганакларының берсе 1 959,1 мең сум күләмендә Кукмара районы бюджеты чаралары, шул исәптән

2018 ел – 0 мең сум,

2019 ел – 0 мең сум,

2020 ел – 1 959,1 мең сум.

Ярдәмче программаны финанс белән тәэмин итү ел саен аныкланырга һәм төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Ярдәмче программаны тормышка ашыру вакыты

Ярдәмче программаны тормышка ашыру срогы – 2018 – 2020 еллар.

Муниципаль ярдәмче программаны башкаручылар

Ярдәмче программаны башкаручылар:

- Авыл җирлекләре башкарма комитетлары.
- Конкурс нигезендә җәлеп ителә торган, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, проект-смета, ремонт-эксплуатация һәм программаны гамәлгә ашыру белән бәйле башка эшчәнлек алып бару хокукына лицензиясе булган оешмалар һәм предприятиеләр.

Муниципаль ярдәмче программаны гамәлгә ашыру барышын тикшереп тору

Әлеге программаның үтәлешен Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты тикшереп тора.

Муниципаль ярдәмче программаны гамәлгә ашыру механизмы.

Ярдәмче программаны гамәлгә ашыру оешмалар һәм предприятиеләр тарафыннан «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә төзелгән контрактлар нигезендә гамәлгә ашырылачак.